# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ҮЗИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

№3 КАРАР

08 ноябрь 2024 ел

«Аксубай муниципаль районы Иске Үзи авыл җирлегенең Иске Үзи авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында"

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районының «Иске Үзи авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы нигезендә

Карар бирәм:

1. 1. 2024 елның 19 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка Иске Үзи авылы мәдәният йорты бинасында Ленин урамы, 2Айорт адресы буенча, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Үзи авыл җирлегенең Иске Үзи авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
Аксубай муниципаль районы Иске Үзи авыл җирлегенең Иске Үзи авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку формасында укучы, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (контракт буенча хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгәннәрне) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш,2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә һәм түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә ризамы:

1. Җирлек торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш сатып алу,шартнамә буенча эшләр өчен түләү);

2. Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, су агызуны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру:

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, алар су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне (электрүткәргечләр, торбалар, тоташмалар һәм башка товарлар сатып алуны)тәэмин итә.;

3. Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, аның предметы җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәү, күрсәтелгән Кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- торак пункт территориясен төзекләндерү (диодлы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру).

РИЗА

КАРШЫ

3. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләрнең күплэп җыела торган урыннарына, стендларга һәм такталарга белдерүләр элү юлы белән халыкка җиткерергә, шулай ук Аксубай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтына һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталына урнаштырырга

Аксубай муниципаль районы
Иске Үзи авыл җирлеге башлыгы: Н.В.Айдова